ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 99-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Г. Әхмәтов, О.М. Воронова, А.Р. Зарипов, С.М. Захарова, Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 99-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 415-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Г. Әхмәтов, О.М. Воронова,
А.Р. Зарипов, С.М. Захарова,
Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева,
М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2025, №33 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«тамашалы чара – тамашалы театр, мәдәни-агарту яисә тамаша-күңел ачу чарасы, шул исәптән музей әйберләрен һәм музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү.»;

2) 17 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унҗиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары белән эчке эшләр органнарына һәм башка кызыксынучы органнарга һәм учреждениеләргә йөкләнгән җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүгә караган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында аларга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тамашалы чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрендә (алга таба – тамашалы чараларның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләре) билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тамашалы чараларның тематикасы, аларны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты, аларга планлаштырылган

килүчеләр саны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында аларны үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмаган срокта йә, тамашалы чара үткәрелү, яисә аның тематикасы, үткәрү урыны, датасы һәм вакыты үзгәрү, яисә аның үткәрелмәячәге турында мәгълүмат кыскарак срокта алынган очракта, кичекмәстән хәбәр итү;»;

б) унҗиденче абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

3) VI бүлектә:

а) бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**VI бүлек. Мәдәният өлкәсен икътисадый җайга салу. Тамашалы чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү**»;

б) түбәндәге эчтәлекле $26^1$ статья өстәргә:

«$26^1$ статья. **Тамашалы чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү**

Тамашалы чаралар тамашалы чараларның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрен һәм тамашалы чаралар үткәрелә торган объектларның һәм (яисә) территорияләрнең террордан якланганлыгына карата таләпләрне үтәп үткәрелә.

Тамашалы чараны оештыру һәм үткәрү йөкләсен үз өстенә алган, шул исәптән тамашалы чараны оештыру, финанс ягыннан һәм башкача тәэмин итүче физик зат яисә юридик зат оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә (алга таба – тамашалы чараны оештыручы) тамашалы чараны оештыру һәм үткәрү максатларында тамашалы чараларның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнә торган тәртиптә һәм рәвештә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына, тиешле җирле үзидарә органына тамашалы чараның тематикасы, тамашалы чара үткәрелә торган объект һәм (яисә) территория, мондый объект һәм (яисә) территория милекчесе (хокукка ия булучысы), тамашалы чараны үткәрү датасы һәм вакыты, аларга планлаштырылган килүчеләр саны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында алдан хәбәр итә һәм тамашалы чараның тематикасы, үткәрү урыны, датасы, вакыты тамашалы чарага килүчеләрнең планлаштырылган саны турында, шулай ук тамашалы чараның үткәрелмәячәге, алмаштырылуы һәм (яисә) күчерелүе турында кичекмәстән җиткерә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы, тиешле җирле үзидарә органы тамашалы чары үткәрү турында хәбәр алганнан соң, шунда ук аның алыну датасын һәм вакытын күрсәтеп, әлеге хәбәрнең алынуын документаль расларга һәм, әлеге Законның 17 статьясындагы унҗиденче абзацы һәм «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-I номерлы Россия Федерациясе Законының 40 статьясындагы икенче – дүртенче өлешләре нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе законнары белән эчке эшләр органнарына һәм башка кызыксынучы органнарга һәм учреждениеләргә йөкләнгән җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүгә, шулай ук тамашалы чараны

үткәргәндә ихтыяҗ булганда кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүгә караган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында аларга хәбәр итүне тәэмин итәргә тиеш.

Үткәрелгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына, тиешле җирле үзидарә органына хәбәр итү таләп ителмәгән тамашалы чараларның категорияләре исемлеге тамашалы чараларның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнә.

Тамашалы чараларны үткәргәндә, шул исәптән спорт корылмаларында, җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-I номерлы Россия Федерациясе Законында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2025, №1 (I өлеш), «мәдәни» сүзен «тамашалы» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Тамашалы чараларны оештыручыларның хокукларын нормативларда беркетү максатларында 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» Россия Федерациясе Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Федераль законның $20^2$ һәм 37 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 апрелендәге 87-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 87-ФЗ номерлы Федераль закон) белән тамашалы чараларны оештырганда һәм үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү үзенчәлекләре билгеләнә. Әйтик, тамашалы чараны оештыручы Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең тиешле органына, җирле үзидарә органына тамашалы чараның тематикасы, тамашалы чара үткәрелә торган объект һәм (яисә) территория, мондый объект һәм (яисә) территория милекчесе (хокукка ия булучысы), тамашалы чараны үткәрү датасы һәм вакыты, аларга планлаштырылган килүчеләр саны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында алдан хәбәр итәргә тиеш.

Моннан тыш, 87-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге органнарына эчке эшләр органнарына һәм башка кызыксынучы органнарга һәм учреждениеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тамашалы чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тамашалы чараларның тематикасы, аларны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты, аларга планлаштырылган килүчеләр саны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында хәбәр итү буенча яңа вәкаләт бирелә.

Аңлауда төрлелек булдырмау максатында закон белән терминология төгәлләштерелә.

Моңа бәйле рәвештә «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү таләп ителә. Охшаш үзгәреш шулай ук «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» 2005 елның 18 августындагы 409 номерлы карарына эчке эшләр органнарына һәм башка кызыксынучы органнарга һәм учреждениеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тамашалы чаралар үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә тамашалы чараларның тематикасы, аларны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты, аларга планлаштырылган килүчеләр саны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүне оештыру буенча планлаштырыла торган чаралар турында хәбәр итү буенча яңа вәкаләт бирү өлешендә үзгәреш кертү таләп ителә.

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.